# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге составына керүче Түбән Наратбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

10.11.2025 № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Түбән Наратбаш торак пункт чикләрендә традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү; торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Бөек Ватан сугышы ядкәрен ремонтлау, кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 10 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны-748 кеше.

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 554 катнашучы кертелде. Тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 409 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 220 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге составына керүче Түбән Наратбаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Түбән Наратбаш торак пункт чикләрендә традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү; торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Бөек Ватан сугышы ядкәрен ремонтлау, кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Түбән Наратбаш авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ___________ Р.Н.Шәрәфетдинов

Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы __________________ Р.Н.Шәрәфетдинов